**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 6 май № 328

г. Казань

Россия Федерациясе төбәкләрендә этномәдәни проектларны тормышка ашыручы иҗтимагый оешмаларга дәүләт ярдәме күрсәтү турында

Россия Федерациясендә татар телен саклау, татар милли мәдәниятен үстерү һәм популярлаштыру, бу өлкәдә гражданнар башлангычларына булышлык күрсәтү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Россия Федерациясе төбәкләрендә этномәдәни проектларны тормышка ашыручы иҗтимагый оешмаларга ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын булдырырга.

Теркәлә торган түбәндәгеләрне расларга:

Россия Федерациясе төбәкләрендә этномәдәни проектларны тормышка ашыручы иҗтимагый оешмаларга дәүләт ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын конкурс нигезендә бирү тәртибен;

Россия Федерациясе төбәкләрендә этномәдәни проектларны тормышка ашыручы иҗтимагый оешмаларга дәүләт ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын конкурс нигезендә бирү буенча совет составын.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\328.doc

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 6 май, 328 нче карары
белән расланган

**Россия Федерациясе төбәкләрендә этномәдәни проектларны тормышка ашыручы иҗтимагый оешмаларга дәүләт ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын конкурс нигезендә бирү тәртибе**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Бу Тәртип этномәдәни проектларны (алга таба – проект) тормышка ашыручы Россия Федерациясе территориясендә, Татарстан Республикасыннан гайре, теркәлгән һәм үз эшчәнлекләрен гамәлгә ашыручы юридик затлар булып тора торган иҗтимагый оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр рәвешендә конкурс нигезендә грантлар бирү механизмын билгели (алга таба – грант, иҗтимагый оешма).

Грантлар бирү «Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы» ведомствосы буенча тиешле финанс елына һәм планлаштырылган чорга Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында күрсәтелгән максатларга каралган бюджет ассигнованияләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары кысаларында гамәлгә ашырыла.

1.2. Грантлар иҗтимагый оешмаларга Россия Федерациясе төбәкләрендә, Татарстан Республикасыннан гайре, гореф-гадәтләрне һәм йолаларны саклау, татар милли мәдәниятен үстерүгә юнәлдерелгән проектларны тормышка ашыру максатларында конкурс нигезендә биреләләр.

1.3. Грант алу хокукына конкурсны (алга таба – конкурс) үткәрүне оештыру Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы (алга таба – вәкаләтле орган) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

1.4. Вәкаләтле орган әлеге Тәртип кысаларында:

конкурс, конкурста катнашучыларга таләпләр һәм аның йомгаклары турында мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге үзенең рәсми сайтында бастырып чыгаруны тәэмин итә;

конкурста катнашуга гаризалар (алга таба – гаризалар) әзерләү мәсьәләләре буенча консультация бирүне оештыра;

гаризаларны һәм аларга теркәлгән документларны кабул итүне оештыра;

бирелгән гаризаларны саклауны тәэмин итә;

Россия Федерациясе төбәкләрендә этномәдәни проектларны тормышка ашыручы иҗтимагый оешмаларга дәүләт ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын конкурс нигезендә бирү буенча совет (алга таба – Совет) эшчәнлеген оештыру-техник яктан тәэмин итүне гамәлгә ашыра;

конкурс җиңүчеләре белән грантлар бирү турында килешүләр төзи;

бирелгән грантларны максатчан файдалануга контрольне гамәлгә ашыра.

## II. Конкурс үткәрүнең төп бурычлары һәм принциплары

2.1. Конкурс үткәрүнең төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

социаль әһәмияттәге бурычларны хәл итүдә Россия Федерациясе төбәкләрендә дәүләт хакимияте органнары һәм иҗтимагый оешмаларның үзара багланышлары формаларын камилләштерү;

иҗтимагый оешмаларның социаль әһәмияттәге эшчәнлеген үстерү һәм дәүләт ярдәме.

2.2. Конкурсны оештыру һәм үткәрү буенча эш түбәндәге принципларга нигезләнә:

гавамлык һәм ачыклык;

иҗтимагый оешмаларның конкурста катнашуга тигез хокуклары;

гаризаларны карап тикшерүнең ярышу, конкурслы нигезе.

## III. Совет оештыру һәм эшчәнлеге тәртибе

3.1. Совет вәкаләтле орган вәкилләре, мәдәният өлкәсендәге белгечләр, җәмәгатьчелек вәкилләре арасыннан Совет рәис, ике рәис урынбасары һәм әгъзалары составында оештырыла.

3.2. Бу Тәртип кысаларында Совет:

гаризаларны бәяләү өчен экспертлар исемлеген төзи һәм раслый;

конкурста катнашу рөхсәт ителгән иҗтимагый оешмалар исемлеген һәм конкурста катнашу рөхсәт ителмәгән иҗтимагый оешмалар исемлеген раслый;

конкурсның җиңүчеләрен һәм аларга бирелә торган грантлар зурлыгын билгели.

3.3. Совет эше аның утырышларында гамәлгә ашырыла. Утырышта Совет әгъзаларының яртысыннан ким булмаган өлеше катнашса, ул тулы хокуклы санала.

3.4. Совет карарлары утырышта ачык тавыш бирүдә катнашучы әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә һәм Совет утырышында катнашкан әгъзалары имзалаган һәм Совет утырышын үткәргән көннән соң бер көн эчендә Совет рәисе раслаган Совет утырышы беркетмәсе белән рәсмиләштерелә. Совет әгъзасының аерым фикере булган очракта әлеге фикер шулай ук Совет утырышы беркетмәсенә кертелә. Тавышлар тигез булган очракта рәислек итүче тавышы хәлиткеч була.

Совет утырышы беркетмәсе беркетмә расланган көннән соң өч эш көненнән дә соңга калмыйча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә вәкаләтле органның рәсми сайтында ачык файдалануга урнаштырыла.

3.5. Совет әгъзасы мәнфәгатьле булган, шулай ук Совет әгъзасына йогынты ясый алган иҗтимагый оешма гариза биргән очракта, Совет әгъзасы Совет эшендә катнашмый.

3.6. Советның оештыру-техник эшчәнлеген яраштыру, утырышларын әзерләү һәм документларын алып бару өчен Совет рәисе вәкаләтле орган хезмәткәрләре арасыннан Совет секретарен билгели.

## IV. Гаризалар бирү тәртибе

4.1. Законнарда билгеләнгән тәртиптә теркәлгән һәм конкурс сайлап алуы игълан ителгән көнгә кадәр бер елдан да ким булмаган вакыт үз эшчәнлекләрен гамәлгә ашыручы, уставлары нигезендә татар халкының, теленең, тарихының мәдәни мирасын пропагандалау; киләчәк буында татар мәдәниятенең этник охшашлыгын формалаштыру буенча социаль, мәгълүмати, мәдәни, белем бирү, фәнни вазыйфаларны тормышка ашыру эшчәнлекләренең төп максатлары булып торган иҗтимагый оешмаларга конкурста катнашу рөхсәт ителә.

4.2. Сәяси партияләр, дәүләт һәм муниципаль уреждениеләр, шулай ук бетерелү яки яңадан төзелү процедурасын үтә торган иҗтимагый оешмалар конкурс катнашучылары була алмыйлар.

4.3. Вәкаләтле орган конкурс үткәрү турында карар кабул итә һәм аны кабул иткән көннән соң өч көн эчендә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә үзенең рәсми сайтында конкурс үткәрү турында белдерү урнаштыра.

Гаризалар кабул итү «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә конкурс үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң 30 көн эчендә гамәлгә ашырыла.

4.4. Конкурста катнашу өчен вәкаләтле органга әлеге Тәртипкә 1 нче кушымта нигезендә форма буенча түбәндәгеләр теркәлгән гариза тапшырыла:

әлеге Тәртипкә 2 нче кушымта нигезендә форма буенча проект;

оешма мөһере һәм җитәкче имзасы белән расланган устав күчермәләре;

проектны бергә финанслау турында гарантия бирә торган хат;

тапшырыла торган документлар исемлеге.

4.5. Проектны тормышка ашыруга чыгымнарның гомуми суммасының 20 процентыннан ким булмаган күләмдә бюджеттан тыш чыганаклар акчасы хисабына проектны финанслау буенча иҗтимагый оешмаларның йөкләмәсе грантлар бирү шарты булып тора.

4.6. Бер иҗтимагый оешма бер генә гариза бирә ала, аның составында конкурста катнашу өчен бер генә проект тапшырыла.

4.7. Гариза һәм аңарга теркәлә торган документлар тегелгән, номер бирелгән һәм мөһер һәм иҗтимагый оешманың вәкаләтле заты имзасы белән расланган булырга тиеш. Барлык документлар да ачык бастырылырга тиеш. Иҗтимагый оешманың мөһере һәм вазыйфаи заты имзасы белән расланган төзәтмәләрдән тыш чистартулар һәм төзәтмәләр рөхсәт ителми.

4.8. Гариза һәм аңарга теркәлә торган документлар кәгазьдә һәм электрон мәгълүмат йөртү җайланмаларында түбәндәге адрес буенча тапшырылалар: 420015, Казан шәһәре, Пушкин урамы, 66/33 йорт, 418 нче бүлмә. Телефон: (843) 264-73-95.

4.9. Гариза кабул иткәндә вәкаләтле орган аны кергән көнендә гаризаларны исәпкә алу журналына терки һәм иҗтимагый оешмага гаризаны кабул итү датасы һәм теркәлү номеры күрсәтелгән гаризаны алу кәгазен бирә.

Гариза вәкаләтле органга почта аша кергәндә ул бер көн эчендә гаризаларны исәпкә алу журналына теркәлә. Бу очракта гаризаны алу кәгазе төзелми, гаризаларны исәпкә алу журналында теркәү датасы итеп почта юлламасында штемпель белән расланган почта юлламасын элемтә оешмасына тапшыру көне күрсәтелә.

4.10. Гаризаларны кабул итү вакыты үткәннән соң вәкаләтле органга кергән гариза (шул исәптән почта аша) теркәлми һәм иҗтимагый оешмага конкурста катнашу рөхсәт ителми.

4.11. Вәкаләтле орган гаризалар кабул итү тәмамланган көннән соң бер көн эчендә барлык кергән гаризаларны Советка тапшыра.

4.12. Бирелгән гаризалар Совет тарафыннан вәкаләтле орган гаризаларны тапшырган көннән соң эш көннәрендә исәпләнелгән биш көн эчендә әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләр нигезендә карап тикшереләләр.

4.13. Совет гаризаны кире кагу турында карар кабул итә, әгәр:

гариза әлеге Тәртип таләпләренә туры килмәсә;

гаризада дөрес булмаган белешмәләр булса;

гариза биргән иҗтимагый оешма әлеге Тәртиптә куелган таләпләргә җавап бирмәсә.

4.14. Конкурста катнашу рөхсәт ителгән иҗтимагый оешмалар исемлеге һәм конкурста катнашу рөхсәт ителмәгән иҗтимагый оешмалар исемлеге Совет утырышы беркетмәсе белән рәсмиләштереләләр.

4.15. Совет утырышы беркетмәсен раслаганнан соң конкурста катнашучылар исемлеге, шулай ук конкурста катнашу рөхсәт ителмәгән иҗтимагый оешмалар исемлеге эш көннәрендә исәпләнелгән өч көн эчендә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә вәкаләтле органның рәсми сайтында урнаштырыла.

4.16. Конкурста катнашучылар исемлеген раслаганнан соң Совет гаризаларны һәм аңарга теркәлгән документларны эш көннәрендә исәпләнелгән өч көн эчендә Совет тарафыннан расланган экспертлар исемлегенә кертелгән экспертлар карап тикшерүенә тапшыра.

## V. Гаризаларны эксперт бәяләве һәм конкурсның җиңүчеләрен билгеләү

5.1. Һәр проектны ике эксперт карап тикшерә. Экспертлар проектларны әлеге Тәртипнең 5.2 пунктында билгеләнгән критерияләр нигезендә бәялиләр. Әгәр проектны карап тикшергән экспертлар бәяләве 35 һәм аннан күбрәк баллга аерылып торса, проект Совет билгели торган өченче эксперт тарафыннан карап тикшерелә.

5.2. Гаризаларны бәяләү түбәндәге категорияләр буенча 10 баллы шкала (0дән 10га кадәр) буенча гамәлгә ашырыла:

| Т/с | Гаризаларны бәяләү критерияләре | Бәя (баллар) |
|---|---|---|
| 1 | Проектның әһәмияте һәм актуальлеге критерияләре | |
| 1.1 | Проектның конкурс үткәрү бурычларына туры килүе | Баллар саны тапшырылган проектны, гаризаның бүтән документларын бәяләү нәтиҗәләре буенча экспертлар тарафыннан билгеләнә – 0дән 10га кадәр |
| 1.2 | Проект хәл итүгә юнәлдерелгән | Баллар саны тапшырылган проектны, |

| | | |
|---|---|---|
| | мәсьәләләрнең актуальлеге | гаризаның бүтән документларын бәяләү нәтиҗәләре буенча экспертлар тарафыннан билгеләнә – 0дән 10га кадәр |
| 1.3 | Проект чараларының акылга ятышлы, үзара бәйләнеше һәм эзлекле булуы | Баллар саны тапшырылган проектны, гаризаның бүтән документларын бәяләү нәтиҗәләре буенча экспертлар тарафыннан билгеләнә – 0дән 10га кадәр |
| 2 | Икътисадый нәтиҗәлелек критерияләре | |
| 2.1 | Проектны тормышка ашыруга планлаштырылган чыгымнарның һәм аның көтелә торган нәтиҗәләренең чагыштырмасы | Баллар саны тапшырылган проектны, гаризаның бүтән документларын бәяләү нәтиҗәләре буенча экспертлар тарафыннан билгеләнә – 0дән 10га кадәр |
| 2.2 | Проектны тормышка ашыруга чыгымнарның нигезле булуы | Баллар саны тапшырылган проектны, гаризаның бүтән документларын бәяләү нәтиҗәләре буенча экспертлар тарафыннан билгеләнә – 0дән 10га кадәр |
| 2.3 | Проектны тормышка ашыруга бюджеттан тыш чыганаклардан көтелә торган керемнәр күләме, акча, бүтән мөлкәтне, милек хокукларын, түләүсез башкарылган эшләрне һәм күрсәтелгән хезмәтләрне, ихтыяри эшләүчеләр хезмәтен дә кертеп (проектны тормышка ашыруга чыгымнарның гомуми суммасыннан 20 проценттан ким түгел) | Баллар саны тапшырылган проектны, гаризаның бүтән документларын бәяләү нәтиҗәләре буенча экспертлар тарафыннан билгеләнә – 0дән 10га кадәр |
| 3 | Проектның социаль нәтиҗәлелегә критериясе | |
| 3.1 | Проектны тормышка ашыруның нәтиҗәлелеге күрсәткечләре булу, аларның проектның бурычларына туры килүе | Баллар саны тапшырылган проектны, гаризаның бүтән документларын бәяләү нәтиҗәләре буенча экспертлар тарафыннан билгеләнә – 0дән 10га кадәр |
| 3.2 | Планлаштырылган чараларның проектны тормышка ашырудан көтелүче нәтиҗәләргә туры килүе | Баллар саны тапшырылган проектны, гаризаның бүтән документларын бәяләү нәтиҗәләре буенча экспертлар тарафыннан билгеләнә – 0дән 10га кадәр |

| | | |
|---|---|---|
| 3.3 | Проект чараларының максатчан төркем хәлен яхшыртуга тәэсир итү дәрәҗәсе | Баллар саны тапшырылган проектны, гаризаның бүтән документларын бәяләү нәтиҗәләре буенча экспертлар тарафыннан билгеләнә – 0дән 10га кадәр |
| 4 | Критерии профессиональной компетенции | |
| 4.1 | Иҗтимагый оешманың проект буенча күздә тотыла торган эшчәнлекне гамәлгә ашыру тәҗрибәсе булу | Баллар саны тапшырылган проектны, гаризаның бүтән документларын бәяләү нәтиҗәләре буенча экспертлар тарафыннан билгеләнә – 0дән 10га кадәр |
| 4.2 | Иҗтимагый оешманың проектны тормышка ашыру өчен кирәкле матди-техник базасы һәм урыны булу | Баллар саны тапшырылган проектны, гаризаның бүтән документларын бәяләү нәтиҗәләре буенча экспертлар тарафыннан билгеләнә – 0дән 10га кадәр |
| 4.3 | Иҗтимагый оешманың максатчан керемнәрне куллану тәҗрибәсе булу | Баллар саны тапшырылган проектны, гаризаның бүтән документларын бәяләү нәтиҗәләре буенча экспертлар тарафыннан билгеләнә – 0дән 10га кадәр |
| 5 | Өстәмә критерияләр | |
| 5.1 | Проект челтәр партнерлыгында үсеш ала | юк – 0,<br>ике иҗтимагый оешманың челтәр партнерлыгында – 1,<br>иҗтимагый оешма һәм бизнесның челтәр партнерлыгында – 2,<br>иҗтимагый оешма, бизнес һәм хакимиятнең челтәр партнерлыгында – 3,<br>иҗтимагый оешма, бизнес хакимият, һәм массакүләм мәгълүмат чараларының челтәр партнерлыгында – 4 |
| 5.2 | Проект берничә муниципаль район һәм/яки шәһәр округы территориясендә тормышка ашырыла | юк – 0,<br>2 муниципаль берәмлектә – 1,<br>3 һәм күбрәк муниципаль берәмлектә – 3 |
| 5.3 | «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә иҗтимагый оешманың эшләнгән сайты булу | юк – 0,<br>әйе – 1. |

5.3. Экспертларга Совет тарафыннан гаризалар тапшырылган көннән соң эш көннәрендә исәпләнелгән ун көн эчендә алар гаризаларны һәм аларга теркәлгән

документларны карап тикшерәләр һәм эксперт бәяләмәләрен Советка тапшыралар.

5.4. Гаризаларга эксперт бәяләве үткәрү барышында экспертка билгеле булган мәгълүмат сер итеп саклана торган була һәм таратылырга тиеш түгел.

5.5. Эксперт бәяләмәләрен алганнан соң Совет эш көннәрендә исәпләнелгән өч көн эчендә конкурста катнашучы җиңүче дип танылырга мөмкин булган гариза рейтингының иң аз күрсәткечен билгеләү (алга таба - гариза рейтингының иң аз күрсәткече) һәм һәр критерия буенча баллар суммасы буенча гаризалар рейтингын (ул һәр критерий буенча баллар суммасыннан уртача арифметик булып исәпләнелә) формалаштыру өчен эксперт бәяләмәләрен вәкаләтле органга тапшыра.

5.6. Вәкаләтле орган эксперт бәяләмәләрен алган көннән соң эш көннәрендә исәпләнелгән өч көн эчендә гариза рейтингының иң аз күрсәткечен билгели һәм гаризалар рейтингын формалаштыра.

Гариза рейтингының иң аз күрсәткече түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$M = \frac{ОКБ}{N},$$

монда:

$M$ – гариза рейтингының иң аз күрсәткече;

$ОКБ$ – конкурста катнашучылар җыйган балларның гомуми суммасы;

$N$ – конкурста катнашучылар саны.

Гариза рейтингының иң аз күрсәткечен исәпләгәннән соң эш көннәрендә исәпләнелгән биш көн эчендә вәкаләтле орган номиналь коэффициент һәм гариза рейтингының чик күрсәткечен билгеләү зурлыгы турында карар кабул итә (алга таба – гариза рейтингының чик күрсәткече).

Гариза рейтингының чик күрсәткече түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$P = M \times K,$$

монда:

$P$ – гариза рейтингының чик күрсәткече;

$M$ – гариза рейтингының иң аз күрсәткече;

$K$ – Совет карар белән билгеләнә торган 1гә тигез, 0,01гә арту адымы белән, номиналь коэффициент.

5.7. Гариза рейтингының чик күрсәткечен билгеләгәннән һәм гаризалар рейтингын формалаштырганнан соң вәкаләтле орган эш көннәрендә исәпләнелгән өч көн эчендә Советка гариза рейтингының чик күрсәткечен һәм формалаштырылган гаризалар рейтингын тапшыра.

5.8. Совет эш көннәрендә исәпләнелгән биш көн эчендә конкурсның җиңүчеләрен билгели һәм әлеге Тәртипнең 6.1 пункты нигезендә аларга бирелә торган грантлар зурлыгын раслый.

5.9. Конкурс сайлап алуы йомгаклары (бирелә торган субсидияләр күләмен күрсәтеп, конкурс җиңүчеләренең расланган исемлеге) расланган көннән соң эш көннәрендә исәпләнелгән биш көн эчендә вәкаләтле орган тарафыннан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә рәсми сайтында урнаштырыла.

## VI. Грантларны бирү һәм куллану

6.1. Грантларны иҗтимагый оешмалар арасында бүлү түбәндәге формула буенча гамәлгә ашырыла:

$$C_i = \frac{S}{SUM} \times a_i,$$

монда:

$C_i$ – i-иҗтимагый оешма – конкурс җиңүчесенә грант күләме;

$S$ – грантның гомуми күләме;

$SUM$ – билгеләнгән тәртиптә конкурс җиңүчеләре дип танылган барлык иҗтимагый оешмалар җыйган баллар суммасы;

$a_i$ – экспертлар бәяләве буенча i-иҗтимагый оешма – конкурс җиңүчесе җыйган баллар суммасы.

6.2. Конкурс җиңүчеләре исемлеге расланган көннән соң календарь көннәрендә исәпләнелгән 30 көн эчендә вәкаләтле орган конкурс җиңүчеләре белән вәкаләтле орган тарафыннан раслана торган форма буенча грант бирү турында килешү төзи. Килешүдә грант зурлыгы, аның максатчан билгеләнеше, аны күчерү тәртибе һәм сроклары, аны куллану турында хисап бирү тәртибе һәм сроклары, әлеге Тәртиптә күрсәтелгән очракларда грантны кире кайтару тәртибе, вәкаләтле орган, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан грант бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүгә тикшерүләр оештыруга иҗтимагый оешманың ризалыгы, килешү шартларын бозган өчен җаваплылык күздә тотыла.

Вәкаләтле орган тарафыннан грант күчерү яклар килешүгә имза куйган көннән соң эш көннәрендә исәпләнелгән ун көн эчендә иҗтимагый оешманың исәп-хисап счетына килешү нигезендә гамәлгә ашырыла.

Иҗтимагый оешма грант килү һәм аны тоту буенча аерым бухгалтер исәбе алып бара.

## VII. Вәкаләтле орган карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять бирү тәртибе

7.1. Иҗтимагый оешма вәкаләтле орган гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) тәртиптә шикаять бирергә хокуклы.

7.2. Вәкаләтле орган гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять биргәндә иҗтимагый оешма вәкаләтле орган җитәкчесенә яки аның вазыйфаларын башкаручы затка мөрәҗәгать итәргә, ә иҗтимагый оешма карап тикшерү нәтиҗәләре белән канәгатьләнмәгән очракта Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

7.3. Иҗтимагый оешманың вәкаләтле орган гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятен бирү һәм карап тикшерү «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карап тикшерү тәртибе турында» 2006 ел, 2 май, 59-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

7.4. Иҗтимагый оешма вәкаләтле орган карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә шикаять бирергә хокуклы.

## VIII. Грант алучылар тарафыннан хисаплар бирү һәм грантларны кире кайтару тәртибе

8.1. Грант алучылар хисап елының 1 декабренә кадәр вәкаләтле органга, фото- һәм видеоматериаллар теркәп, грантны максатчан файдалану турында хисап тапшыралар.

Грантны максатчан файдалану турында хисапта түбәндәгеләр күрсәтелә:

проектны тормышка ашыру кысаларында үткәрелгән чараларның (алга таба – чаралар) социаль әһәмияте;

чараларда катнашучылар саны;

чаралар турында җәмәгатьчелек фикеренә күзәтү (массакүләм мәгълүмат чаралары хәбәрләре).

8.2. Түбәндәге очракларда акчаны куллану турында хисап тапшырылган көннән соң 60 көн эчендә грантлар Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш:

грант алучылар тарафыннан дөрес булмаган белешмәләр бирелсә;

грант бирү шартлары үтәлмәсә;

грантлар максатчан кулланылмаса.

8.3. Иҗтимагый оешма тарафыннан грантны максатчан кулланмау факты билгеле булган көннән соң календарь көннәрендә исәпләнелгән ун көн эчендә вәкаләтле орган иҗтимагый оешмага грантны максатчан кулланмау факты билгеле булу турында белдерә.

8.4. Иҗтимагый оешма грантны кире кайтару өчен билгеләнгән вакытны бозганда әлеге Тәртипнең 8.2 пунктында күрсәтелгән срок тәмамланган көннән соң 30 көн эчендә вәкаләтле орган Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә грантны Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча чаралар күрә.

8.5. Хисап финанс елында иҗтимагый оешма тарафыннан кулланылмый калган грант өлеше Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

8.6. Грант алучылар тарафыннан аларны бирүнең шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүгә, грантларны максатчан куллануга контрольне Россия Федерациясе законнарында билгләнгән тәртиптә мәҗбүри тикшерүләр үткәрү юлы белән Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Финанс  министрлыгы гамәлгә ашыра.

---

Россия Федерациясе төбәкләрендә этномәдәни проектларны тормышка ашыручы иҗтимагый оешмаларга дәүләт ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын конкурс нигезендә бирү тәртибенә 1 нче кушымта

Форма

Россия Федерациясе төбәкләрендә этномәдәни проектларны тормышка ашыручы иҗтимагый оешмаларга дәүләт ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын алу хокукына конкурста катнашырга
ГАРИЗА

1. Гариза бирүче оешма исеме, ИНН:
______________________________________________________________________

2. Адрес: _________ ______________________________________________________
(индекс) (юридик адрес)
_________ __________________ E-mail: ______________________________________
(телефон) (факс)

3. Оешма җитәкчесе фамилиясе, исеме, атасының исеме:
______________________________________________________________________
тел.:___________________
Адрес: _____________________________________ E-mail: ____________________

4. Гариза бирүче оешма гамәлгә ашыра торган эшчәнлек төрләре турында мәгълүмат:
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________

5. Проект исеме: ________________________________________________________
Проектның юнәлеше: _____________________________________________________
Проектның авторы: ______________________________________________________
Элемтә өчен мәгълүмат:
______________________________________________________________________

6. Элек оешма федераль, төбәк яки җирле бюджеттан грант алганмы? Алган булса, проектның елын һәм исемен, грант атамасын һәм суммасын күрсәтегез:
______________________________________________________________________

7. Проектка кыскача аннотация (100 сүз чамасы)
Мәсьәләнең тасвирламасы:__________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________

Проектның максаты һәм бурычлары:___________________________________
Чаралар планы: _________________________________________________________

Проектны тормышка ашыруга җәлеп итәргә планлаштырылган ирекleләр саны:______
Көтелүче нәтиҗәләр:_____________________________________________________
Проектның бюджеты: _____________________________________________________
Проектның кирәклеген нигезләү: ____________________________________________

8. Оешманың түләү реквизитлары
Банк исеме: _______________________________________________________
адресы:
______________________________________________________________________________
р/с:
______________________________________________________________________________
Гаризада, проект тасвирламасында китерелгән бөтен мәгълүмат, шулай ук өстәмә материаллар дөрес һәм төгәл икәнлекне белдерәм һәм Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының бездән һәм дәүләт һәм муниципаль хакимият органнарыннан тапшырылган белешмәләрне тәгаенлаучы мәгълүматны соратып алырга хокукын раслыйм.

Җитәкче фамилиясе, исеме,
атасының исеме _________________________ /_______________________________/
(имза) (имзаның аңлатмасы)
М.У.

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 ел, 27 июль, 152-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә минем шәхси белешмәләремне файдалануга каршы кимим.

Җитәкче фамилиясе, исеме,
атасының исеме _________________________ /_______________________________/
(имза) (имзаның аңлатмасы)
М.У.

Дата: _________________________

Россия Федерациясе төбәкләрендә этномәдәни проектларны тормышка ашыручы иҗтимагый оешмаларга дәүләт ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын конкурс нигезендә бирү тәртибенә 2 нче кушымта

Форма

Россия Федерациясе төбәкләрендә этномәдәни проектларны тормышка ашыручы иҗтимагый оешмаларга дәүләт ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын алу хокукына конкурста катнашуга проектның тасвирламасы

(5 биттән артык түгел)

1. Проектны тормышка ашыру башланганда социаль-мәдәни өлкәдә Россия Федерациясе төбәгендәге хәлгә гомуми характеристика (1 биттән артык түгел):

| |
|---|
| |

2. Проектның максатлары һәм бурычы:

| |
|---|
| |

3. Проектның төп чаралары тасвирламасы, тормышка ашыру этаплары һәм сроклары:

| Т/с | Тормышка ашыру этабы | Чара исеме | Тормышка ашыру сроклары |
|---|---|---|---|
| | | | |
| | | | |

4. Проектны тормышка ашыру белән идарә итү механизмы:

| |
|---|
| |

5. Күздә тотылган керемнәр һәм планлаштырылган чыгымнар сметасы, аны нигезләү:
Чыгымнарның гомуми суммасы (сум):
Соратылган субсидияләр зурлыгы (сум):
Күздә тотылган бергә финанслау суммасы (сум):

| Т/с | Чыгымнар исеме | Үз һәм җәлеп ителгән акча | Соратылган акча | Барлы-гы |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |
| Барлыгы: | | | | |

Комментарияләр:____________________________________________________________
________________________________________________________________________

6. Проектны реализацияләү нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең мәгънәсе:

| Т/с | Нәтиҗәлелек күрсәткече | Күрсәткеч мәгънәсе |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |

7. Партнерлар турында мәгълүмат:

| |
|---|
| |

Проектка кушымталар CD, DVD-йөртүчеләрдә, электрон һәм басма төрләрдә (видеоматериаллар, фотографияләр, басма продукция һ.б.) тапшырылалар.

Җитәкче фамилиясе, исеме,
атасының исеме __________________________________/______________________/
(имза)

М.У.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 6 май, 328 нче карары
белән расланган

**Россия Федерациясе Төбәкләрендә этномәдәни проектларны тормышка ашыручы иҗтимагый оешмаларга дәүләт ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын конкурс нигезендә бирү советы**
**СОСТАВЫ**

| | |
|---|---|
| Сибагатуллин Айрат Миңнемулла улы | Татарстан Республикасы мәдәният министры, Совет рәисе |
| Гыйлметдинов Илдар Ирек улы | Татарларның федераль милли-мәдәни автономиясе Советы рәисе, Совет рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Закиров Ринат Зиннур улы | «Бөтендөнья татар конгрессы» төбәкара иҗтимагый оешмасы рәисе, Совет рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Совет әгъзалары: | |
| Әхмәтҗанова Лилия Марс кызы | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының милли белем бирү идарәсе башлыгы |
| Айтуганова Миләүшә Ләбиб кызы | «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте генераль директоры урынбасары (килешү буенча) |
| Бәдретдинова Алинә Хәмзә кызы | Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаментының Милли сәясәтне тормышка ашыру идарәсе баш киңәшчесе (килешү буенча) |
| Вәлиев Рафаэль Миргасыйм улы | «Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университеты» югары профессиональ белемнең федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе проректоры, тарих фәннәре докторы, профессор (килешү буенча) |
| Габдрахманова Гөлнара Фаат кызы | Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Ш.Мәрҗәни исемендәге тарих институтының Этносоциологик тикшеренүләр үзәге җитәкчесе, социология фәннәре докторы |

| | |
|---|---|
| Завгарова Фәнзилә<br>Хәким кызы | «Традицион мәдәниятне үстерү республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе җитәкчесе |
| Корбанов Рәфис<br>Харис улы | Татарстан Республикасы Язучылар берлеге рәисе (килешү буенча) |
| Миңнуллин Ким<br>Мөгаллим улы | Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры |
| Нигъмәтуллина Гүзәл<br>Азат кызы | Татарстан Республикасы мәдәният министры урынбасары |
| Нигъмәтуллина Гөлшат<br>Рәдиф кызы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Мәдәният һәм Татарстан Республикасы халыклары телләрен үстерү идарәсе башлыгы |
| Таишев Марсель<br>Мәзһәр улы | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет рәисе (килешү буенча). |

---

F:\KARAR\2015\328.doc